# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

№ 13 «20» декабрь 2021 ел

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль
районы Бәйрәкә авыл җирлегендәге Бәйрәкә
торак пунктында гражданнар җыены
нәтиҗәләре турында

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 131-ФЗ санлы Федераль законның 25.1, 56 маддәләре, 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 45-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы Законының 35 маддәсе нигезендә, 2021 елның 16 декабрендә узган гражданнар җыены беркетмәсе төзелде: «2022 елда Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Бәйрәкә авыл җирлеге Бәйрәкә торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән, балигъ булган һәр кешедән, көндезге бүлектә укучы студентлар, 1 төркем инвалидлар, ветераннар һәм Бөек ватан сугышында катнашучылар, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол калган тормыш иптәшләренннән тыш, 500 (биш йөз) сум күләмендә, түләү суммасын 250 (ике йөз илле) сумга киметеп, 2 төркем инвалидларга үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме:

- Юлларны грейдерлаштыру һәм кардан чистарту (ягулык сатып алу, трактористы белән техника арендалау, килешү нигезендә эшләр өчен түләү);
- Бәйрәкә авылының Пушкин урамындагы юл-урам челтәрен норматив торышка китерү (смета нигезендә юл төзү: вак ком-таш катнашмасы, асфальт сатып алу, нигез әзерләү, алып кайту, салу, эшләр өчен түләү);
- Бәйрәкә авылының административ бина территориясен төзекләндерү (койма урнаштыру, килешү нигезендә эшләр өчен түләү; агачлар, чәчәкләр, куаклар сатып алу һәм утырту);
- Бәйрәкә авылындагы 8 Март урамында урнашкан зират территориясе коймасын ремонтлау (төзелеш материаллары сатып алу, эшләр өчен килешү нигезендә түләү);
- Бәйрәкә авылында урамнарны яктырту объектларын карап тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү (лампалар, энергияне саклаучы лампалар, электр товарлары сатып алу һәм урнаштыру, агымдагы ремонт һәм урам яктырткычларына хезмәт күрсәтү);
- Бәйрәкә авылында корыган агач, куакларны кисү, авыл территориясен җыештыру (килешү нигезендә эшләр өчен түләү);
- Бәйрәкә авылында Бөек Ватан сугышында һәлак булган сугышчылар монументына алып баручы парад баскычын алыштыру (төзелеш материаллары сатып алу, эшләр өчен түләү, килешү нигезендә эшләр өчен түләү).”

Халык җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 895 кеше кертелгән, тавыш бирүдә 453 кеше катнашты, бу 50,6% тәшкил итә.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның